وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№7 (150). 17 август 2012 / 29-рамазан-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ




Ислам дине нәрсәдән башлана?

▷2-3◁



Коръән – Исламның иң төп чыганагы

▷3-4◁



Казан ислам көллияте укырга чакыра

▷4◁


# УРАЗА БӘЙРӘМЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

***Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әссәләәмүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәәтүһ!***

**Әлһәмдүлилләһ! Өстебездә булган бер фарызны үти алуыбызга - ураза тотуыбызга шатлана торган Гает көненә җиттек. Бөтендөнья мөселманнарының зур бәйрәме - Ураза бәйрәме мөбарәк булсын!**




Ихлас күңелдән изге гамәлләр кылырга, сабыр булырга өйрәтүче, рухыбызны тәрбияли торган изге Рамазан-шәриф ае тәмамланды. Ай дәвамында Аллаһы Тәгалә каршында рухи ныклыгыбызны күрсәтергә тырыштык, Аллага шөкер. Ризыктан гына түгел, начар сүзләрдән, гамәлләрдән, фикерләрдән тыелып тордык. Мәчетләребезгә җыелып тәравих намазларын укыдык, ифтар мәҗлесләрендә догалар кабатладык, зекерләр әйттек. Аллаһы Раббыбыз изге Рамазан аенда тоткан уразаларыбызны, укыган намазларыбызны, кылган изге гамәл-гыйбадәтләребезне кабул итеп, барыбызны да җәһәннәм газабыннан коткарып, Үзенең җәннәтләре белән бүләкләсә иде! Аллаһы Тәгалә безгә көч-куәт биреп, динебезгә, халкыбызга, Ватаныбызга хезмәт итәргә ярдәм итсә иде! Рамазанда кылган игелекле гамәлләребез дәвамлы булсын!

Ураза бәйрәме һәр йортка, һәр гаиләгә бәрәкәт, рухи ныклык, сабырлык һәм якты өметләр алып килсен. Киләсе Рамазанны да исән-сау каршы алырга, уразалар тотарга насыйп итсен!

*Олы хөрмәт һәм изге догалар белән, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,мөфти*
***Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# Алтын Урдада ислам дине кабул ителү мәсьәләсе

**БАШЛАП** шуны әйтергә кирәк: үз вакытында күренекле Шәрык тарихы буенча белгеч, Россия ватандашы В.В. Бартольд Җучи Олысында, ягъни, Алтын Урдада, ислам диненең җиңеп чыгуын "күбрәк Идел буе болгарлары йогынтысы" белән түгел, ә Харәзем һәм Урта Азия төркиләре белән бәйләүне кулайрак күргән иде. Һәм шушы фикерне дәлилләү өчен, ул Бәркә ханның (1257-1266) ислам динен кабул итүендә Урта Азия шәехләренең ролен дә күрсәткән иде. Инде бүген бу фикерне тирәнрәк тә нигезләргә була. Мәсәлән, Чыңгыз ханның улы Җучи - Алтын Урдага нигез салучы шәхес. Ул мөселманнар белән бик иртә бәйләнешкә керә һәм кайбер чыганаклар буенча үзенең улы Бәркәне мөселман хатынына тәрбиягә бирә, аңа "мөселман сөтен" имезергә боера (Җүҗани). Ә ул бераз үскәч, аңа белем бирү өчен, мөселман имамнары чакыртыла һәм Бәркәгә Коръән укытыла. Үсеп җиткән Бәркә мөселманга әйләнә һәм аның карамагына мөселманнардан торган 30 меңлек гаскәр бирелә. Исламны Бәркә генә түгел, аның хатыны Чәчәк хатын һәм туганнарының бер өлеше дә кабул итә. Бу вакыйгалар Кубравийа тарикате тарафдары Сәйф-ед-Дин әл-Бохарзи катнашында бара.

Гомумән, монголлар Урта Азияне яулап ала башлагач, андагы кайбер шәехләр һәм аларның тарафдарлары монгол-татарлар ягына чыгып, аларның ышанычларын бик тиз казана. Үз чиратында, аларның үзүзләрен шушы рәвешчә тотуларының геосәяси сәбәпләре була: Багдад хәлифе белән Харәзем шаһлары арасында бу чорда бик нык дошманлык булу сәбәпле (көрәш Иран җирләре өчен барган), хәлиф кушуы буенча, шәехләрнең бер өлеше, монголлар ягына чыгып, гарәпләрнең көндәшләре - Харәзем шаһларының дәүләтләрен җимерергә ярдәм итәләр. Булган мәгълүматларга караганда, бу шәехләр арасында Әхмәт Ясәви тарафдарлары төп урынны тоткан. Шуңа күрә, болай да зур-зур төбәкләрендә мөселманнар яшәгән Алтын Урдада (Урта Азиядә, Болгар олысында, Төньяк Кавказның кайбер районнарында) Бәркә хан заманында ук ислам йогынтысы көчәя башлый.

Ләкин бу әле яңа дәүләттә ислам тарафдарлары XIII йөздә үк җиңеп чыкканнар дигән сүз түгел, чөнки монгол-татарлар арасында иске дин (мәҗүсилек белән бәйле шаманлык) белән бергә "уйгырлар дине", ягъни буддизм көчәя башлый. Шулай да ислам диненең йогынтысы ил эчендә көннән-көн арта бара. Әйтик, күп кенә гарәп чыганаклары Алтын Урда тәхетенә 1280 елны утырган Туда-Менгуның 1283-1284 елларны ислам динен кабул итүе турында язалар. Инде Бәркә хан дәвереннән үк ислам дине тарафдарлары белән башка дин тотучы татар-монгол аристократиясе арасында каршылыклар көчәя башлый - бу турыда Токта хан (1290-1312) белән атаклы Ногайның көрәше вакытында соңгысының ислам диненә таянырга тырышуы да сөйли. Әмма Токта хан да гел "потларга табынып, уйгырларны, ягъни ламаларны һәм сихерчеләрне яратып, аларга ихтирам күрсәтеп кенә" яшәмәгән, ахрысы. Эш шунда ки, күптән түгел табылган кайбер (һиҗри белән 706 һәм 707 нче елларда сугылган) тәңкәләр (1306-1307, 1307-1308) Токта ханның "гыйас ад-дин" (динне коткаручы) һәм "солтан ала?зам гыйас ад-дөнья" ("дөньяны коткаручы иң бөек солтан") дигән мөселман ләкабләре бар! Ә гарәп елъязмачысы Әл-Мөфаддаль инде һиҗри белән 704 елны ук (1304-1305) бу хан турында: "Ул мөселман иде", - дип язган. Димәк, бу мәсьәлә әле тагын тикшерүне

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

**ДМИТРИЙ МЕДВЕДЕВ ТАТАРСТАН МӨФТИЕН УРАЗА ГАЕТЕ БЕЛӘН КОТЛАДЫ**

**"Бу - бөтендөнья мөселманнары өчен иң мөһим дини бәйрәмнәрнең берсе", - диелә котлауда.**

"Хөрмәтле мөфти!

Сезне изге Рамазан ае тәмамлану һәм Ураза гаете бәйрәме белән ихлас күңелемнән котлыйм. Бу - бөтендөнья мөселманнары өчен иң мөһим дини бәйрәмнәрнең берсе. Рамазан ае - ул рухи яктан камилләшү һәм мохтаҗларга ярдәм итү чоры.

Бүген Россия мөселман дөньясы чын-чынлап яңарыш кичерә. Яңа мәчетләр салына, университетлар һәм мәдрәсәләр булдырыла. Безнең күп милләтле һәм күп конфессияле дәүләтебездә традицион ислам тарафдарларының илнең иҗтимагый тормышында актив катнашулары әһәмияткә лаек. Алар үзләренең хәйриячелек һәм агарту эшчәнлеге белән Россиядә гражданнар арасында тынычлыкны һәм бердәмлекне сакларга ярдәм итәләр.

Сезгә һәм барлык мөселманнарга сәламәтлек, иминлек һәм барлык изге теләкләр телим", - диелә Д.Медведев котлавында.

**ХАҖГА ГАРИЗАЛАР 20 АВГУСТКА КАДӘР КАБУЛ ИТЕЛӘ**

**20 август - 2012 елда хаж сәфәренә бару өчен гаризалар кабул итүнең һәм килешүләр төзүнең соңгы көне.** Шуннан соң гаризалар кабул ителмәячәк. Согуд Гарәбстаны корольлегенең Мәскәүдәге илчелегендә визаларны рәсмиләштерү башлану сәбәпле, 1 сентябрьгә кадәр барлык документларны китереп җиткерергә һәм акчаны тулысынча түләргә кирәк булачак.

**19 АВГУСТ - УРАЗА ГАЕТЕ**

**Быел рамазан ае 18 августта кояш баю белән тәмамлана һәм мөселманнарның Ураза бәйрәме - Гает көне 19 августка туры килә.** Бу көнне мәчетләргә җыелып, гает намазын уку һәм бәйрәм вәгазен тыңлау саваплы, күркәм гамәлләрдән санала.

19 августта, Казанның Кол Шәриф мәчетеннән кала, Татарстанның барлык мәчетләрендә дә гает вәгазе иртәнге сәгать алтыда (6.00) башланачак. Кол Шәрифтә - иртәнге сәгать җидедә. Биредә уздырылачак төп бәйрәм чарасы "Татарстан - Яңа гасыр" телеканалы аша трансляцияләнәчәк.

Гает намазы укылып, бәйрәм хөтбәсе тыңланганнан соң, мәчеткә җыйналган халык бер-берсен, анныры якыннарын һәм башкаларны бәйрәм белән тәбрик итә. Бу көнне туганнар, дуслар белән аралашу, бер-береңнең хәлен белешү саваплы гамәлләрдән санала.

**ЯҢА МӘЧЕТ АЧЫЛАЧАК**

**19 август - Ураза гаете көнне - көндезге сәгать уникедә Алексеевск районының Кыр Шынталысы авылында Хәмзә мәчете ачылачак.** Әлеге мәчет "Сельхозснаб" ширкәте директорлар советы рәисе Фәнис Гатин иганәчелегендә төзелгән. Ачылыш тантанасында район хакимияте вәкилләре, авыл халкы катнашыр дип көтелә.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***



# Алтын Урдада ислам дине кабул ителү мәсьәләсе

(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)

таләп итсә дә, Токта ханның XIV йөз башларында ислам динен кабул иткән булуын инкарь итеп булмый. Билгеле булганча, ул хан аннан соң тәхеткә утырган Үзбәк ханның агасы була һәм, күренә ки, инде XIV йөзнең башында ук Сарай әһелләре арасында ислам дине шактый киң таралган була. Ләкин татар-монгол элитасы әле тулаем ислам динендә булмаган, ул диннең дәүләт диненә әйләнүе Үзбәк хан (1312-1342) дәверенә туры килә. Менә шул турыда күбрәк мәгълүмат биреп китик.

Дөресен әйтик, Үзбәк ханның кайчан ислам динен кабул итүе турында анык кына бер хәбәр дә юк, ул вакыйганы төрле документаль чыганаклар 1312 елдан 1320 елга кадәр барган дип күрсәтә. Әмма аларга ныклы анализ ясап карасаң, бу тарихи датаны төгәлрәк итеп тә билгеләргә була. Түбәндә сүз шул юнәлештә барыр.

1312 елның 9 августында Токта хан, Идел елгасы буенча корабта йөзеп барганда (Сарай шәһәреннән ерак булмаган урында), кинәт кенә үлеп китә. Фарсы тарихчысы Кашани мәгълүматлары буенча, аксөякләр җыелып яңа ханны сайлау турында сөйләшү башлыйлар. Шул җыенда (корылтай булса кирәк) "Сарай әмире" дип аталган шәхес (аның исеме "Котлыг-Тимер" дип бирелә, дөресе "Бай-Тимер" булырга тиеш) тәхеткә Токта ханның Илбасмыш исемле улын күтәрергә тәкъдим итә. Ләкин моның өчен башта Үзбәкне юкка чыгарырга кирәген әйтә (ул вакытта Үзбәк гаскәр белән башка җирләрдә була). Үзбәк тиз арада дәүләтнең башкаласына килә, анда мәҗлескә кергәндә, үзенә куркыныч янау турында кисәтү ала һәм гаскәр урнашкан җирләргә качып китә. Чыганаклардан күренгәнчә, аны үтерергә теләүчеләр Үзбәкнең ислам динен кабул итүенә каршы чыгучылар була. Кашани хәбәренчә, Үзбәк, гаскәр белән кире кайтып, бик күп Чыңгызи солтаннарны үтереп (араларында Токта ханның уллары да була), үзе тәхеткә утыра. Икенче бер фарсы елъязмачысы Хафиз-и Абру күрсәтүенчә, Үзбәк хан "Токта ханның улы белән бергә Чыңгыз хан ыруыннан булган 120 солтанны үтерә". Башка бер гарәп елъязмачысы сөйләвенчә, Үзбәк хан аксөяк татарлар белән бергә "күпсанлы уйгырларны, ягъни, лама һәм сихерчеләрне үтертә, ислам динен тотуны игълан итә" (Шәех әл-Бирзали). Бу вакыйгаларны тасвирлаганда, әле Үзбәк ханның ислам динен кабул итүенең төгәл елы күренми, ләкин каршылыкларның дин тирәсендә барганлыгын ачык билгеләп була.

Әйтик, фарсы тарихчылары Кашани һәм Хафиз-и Абру тасвирлаганча, Үзбәк тәхеткә килгәч, бер өлеш әмирләр аңа болай диләр: "Әй падишаһ, син бит безнең буйсынуны телисең, синең безнең динебездә һәм ышануыбызда ни эшең бар? Һәм ни өчен без, Чыңгыз ханнан калган ясактан (ясадан) һәм тордан (ёсуннан) баш тартып, гарәпләрнең иске диннәрен кабул итәргә тиеш?" Димәк, Алтын Урдада барган ике төркем арасындагы көрәш идеология өлкәсендә булган. Бу көрәштә Үзбәк ханга үзенең ныклы позициясен белдерү кирәк була. Ул моны эшли дә. Ләкин чынбарлыкта Үзбәкнең ислам динен кабул итүе бераз башкачарак барганга охшый.

Гарәп тарихчысы ибне Дукмак күрсәткәнчә, "Токта хан дәверендә дәүләт эшләре белән идарә иткән Котлыг-Тимер (бәкләр бәге. - Автор) [хан үлгәннән соң] Үзбәкнең атасы, Тогрылҗаның хатыны булган (ягъни, Токта ханга кияүгә чыкканчы) өлкән хатынга (исеме - Баялун булган. - Автор) мөрәҗәгать итеп, тәхеткә аны күтәрү турында килешкән... Аннан алда ук тәхеткә утыргач, мөселманлык кабул итү һәм ислам дине юлы буенча бару турында вәгъдә ала". Күренә ки, Үзбәк тәхеткә утырганчы ук ислам дине тарафдарлары тарафыннан чорнап алынган була. Бу юкка гына түгел, кайбер бик ачык булмаган чыганаклардагы язмалардан күренгәнчә, Үзбәк солтанның тәхеткә килгәнче гаскәр белән Харәзем олысында яшәгән булуы мөмкин. Эш шунда ки, Кубравийа тарикате шәехе ?Ала ?ад-Дәүләһ Симани мәгълүматлары буенча, һиҗри белән 710 ел тирәсендә (1310-1311) ислам тарафдары булган, исеме билгесез "Харәзем әмире" белән бер солтан (Үзбәк түгел дип уйлыйбыз) арасында дошманлык булуы билгеле. Ә бу әмир Токта хан тарафыннан инде һиҗри белән 709 елны ук (1309-1310) армия белән җитәкчелек итәргә билгеләнгән Котлыг-Тимер булса кирәк. Кайбер башка чыганаклардан күренгәнчә, Токта ханның варисы итеп билгеләнгән Илбасмыш нәкъ менә Харәземдә үтерелә дә. Бу очракта фетнә коручыларны Котлыг-Тимер белән бәйләү дөрес булыр. Иң кызыгы шунда: бу Токта ханның варисын юк итүчеләр Харәземдәге мөселман шәехләре белән тыгыз бәйләнештә булганнар.

Үзбәк ханның ислам динен кабул итүе төгәл кайсы елны булган соң? Гомумиләштереп әйткәндә, бу вакыйга аның тәхеткә күтәрелүе белән бәйле булырга тиеш. Ләкин монда кайбер проблемалар бар.

Беренче чиратта, бу төрле чыганакларда күрсәтелгән вакыйганы төрле даталар белән бәйләү аркасында килеп чыга. Мәсәлән, "Шәҗәрәт әл-әтрәк" (XV гасыр уртасы) хезмәтендә Үзбәк ханның исламны кабул итүе һиҗри белән 720 елда (1320-1321) дип күрсәтелә. Әмма, безнең фикеребезчә, монда бирелгән дата дөрес түгел. Ни өчен? Беренчедән, рус елъязмаларындагы традиция буенча Үзбәк ханның мөселманга әйләнүе ("обесерменился") 1313 елга карый. Икенчедән, көнчыгыш чыганакларында һәм нумизматик материалларда да без шушы елга якын даталарны очратабыз. Әйтик, Кашани елъязмасында Үзбәк ханның ислам динен кабул итүе турындагы мәгълүмат Алтын Урдадан 1313 елның 8 апрелендә (һиҗри белән 712 ел, 10 зөлхиҗҗә) аннан илчеләр килүе белән бәйле контекстта килеп чыга. Илхани елъязмачылары (фарсы тарихчылары) Банаканти һәм Кашани хезмәтләрендә дә бу хәбәр 1315-1315 еллардан да соң дип билгеләнми, ягъни "Шәҗәрәт әл-әтрәк"тә булган датага каршы килә.

Шушы бәхәсле очракта нумизматик мәгълүматлар беренче урынга чыга. Күптән түгел табылган Мухшы шәһәрендә һиҗри белән 713 елны (1313-1314) сугылган көмеш дирһәмдә Үзбәк ханның мондый титулы бар: "Аллаһы мәрхәмәте буенча гадел солтан". Ә шуңа өстәп тагын ханның ләкабе дә бирелә: "Гыйас ад-дөнья вә-д-дин" ("Дөньяны һәм динне коткаручы / яклаучы"). Бу Үзбәк ханның инде ислам динендә булуы турында сөйли түгелме соң?! Инде соңрак вакытларда сугылган тәңкәләр әлеге мәсьәләдә шөбһә калдырмый. Мәсәлән, һиҗри белән 717 елны (1317-1318) Сарай шәһәрендә сугылган Үзбәк хан исеме язылган тәңкәдә "Лә иләһә илләллаһү Мүхәммәдәр расүлүллаһ" дигән юллар бар. Аннан ике ел алдарак (һиҗри белән 715 елда) сугылган тәңкәдә дә Казанда XIX йөздә яшәгән галим М.Х. Френ язганча, ахрысы, "сөнни символикасы" китерелгән юллар язылган булган. Шулай ук Кырымда табылган мәчет порталына (ул сакланган) аның һиҗри белән 714 елны (1314-1315) "Бөек хан Үзбәк Мөхәммәд (соңгысы ханның мөселманча исеме. - Автор) дәверендә" куелганлыгы уелып язылган.

Шулай итеп, Үзбәк ханның ислам диненә күчүен аның Алтын Урда тәхетенә күтәрелүе белән бер үк вакытта булган дип карау тарихи яктан дөрес булыр. Тәхеткә менү вакыйгасы исә 1312 елның августы белән 1313 елның башы арасында булган дип әйтергә урын бар. Димәк, быелның икенче яртысында безнең милли дәүләтебез булган бөек империя - Җучи Олысында (аның төгәл исеме - Олуг Урда) ислам дине кабул ителүгә 700 ел тула.

Бу гаять зур вакыйга булган: кайбер төрки чыганаклардан күренгәнчә, "солтан Мөхәммәд Үзбәк хан үзенең иле һәм олысы белән Аллаһның мәрхәмәтенә ирешкәндә", хан белән бер үк вакытта ислам динен 70 мең кеше кабул иткән. Сүз, һичшиксез, дәүләтнең өстен катлавы, нәкъ менә татарлар турында бара. Шушы дәвердән башлап безнең бабаларыбыз - урта гасыр татар этносы вәкилләре, инде ислам дине кысаларыннан чыкмаганнар. Татар-нугайда сакланган "дин Үзбәктән калган" дигән сүзләр дә шул турыда сөйли. Сөйләнелгән вакыйгаларда суфи тарикатьләре әһелләре бик актив катнашкан һәм бу турыда аерым язма кирәк. Ләкин шуны әйтеп китик: бу суфилар Әхмәт Ясәви тарикате әһелләре булган һәм алар Харәзем якларыннан (Төркестан, Бакырган шәһәрләре тирәсеннән) килгәннәр. Казан ханлыгы дәверендә анда соңгы сәет булган Кол Шәриф тә Үзбәк ханны исламга күндергән Әхмәд сәет (аның кушаматы - Сәет-Ата) нәселеннән була. Ләкин кабатлап әйтәбез, бу турыда аерым зур мәкалә кирәк.

Инде Үзбәк хан ислам дине кабул итеп, ул динне дәүләт диненә әйләндергәч, Алтын Урда тирәләрендә 1330 елларда булып киткән гарәп сәяхәтчесе ибне Баттута илдә күпсанлы мәчетләр, суфи завияләре, алар каршындагы сансыз шәехләр һәм дәрвишләр турында язып калдырган. Шулай ук ул җәй айларында Биштау янында оештырылган бик зур бер бәйрәмне тасвирлаганда, Үзбәк ханның мәчеткә җомга намазына килүе турында да яза.

Билгеле, ислам динен кабул итү бер нәрсә, ә чын мөселманча яшәү - башкачарак. Шуңа күрә дә Үзбәк хан вакытында күп кенә дәүләт структураларын исламлаштыру эшләре башлана. Аның иң әһәмиятле элементларының берсе - һәрбер татар кабиләсенә аерым бер мөселман шәехен беркетеп кую була (үзенә күрә алар эчке "комиссарлар"га әйләнгәннәр). Бу адымнар исә дәүләтне үзәкләштерүгә дә хезмәт иткән. Юкка гына Үзбәк хан һәм аның улы Җанибәк (1342-1357) дәверләре Алтын Урда дәүләтенең иң югары ноктасы дип саналмый.

***Дамир ИСХАКОВ,***
***тарих фәннәре докторы,***
***профессор,***
***Россия Табигый фәннәр академиясе академигы***

# ИСЛАМ ДИНЕ НӘРСӘДӘН БАШЛАНА?

## Шәһадәт – Җәннәткә юл ул

**Шәһадәт китерү** – ул ислам диненең иң беренче һәм иң мөһим баганасы. Шәһадәтне тел белән әйтү һәм аңа күңелең белән ышану – Ислам кабул итүнең шарты булып тора. Ул ике өлештән тора: Аллаһка һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаху галәйһи вә сәлләмгә иман китерү – ***«Әшһәдү әллә* иләһә илләлла*һү вә әшһәдү әннә Мүхәммәдәр расү*лүлла*һ»*** (* – озын сузыклар). *Тәрҗемәсе: «Мин Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәткә лаеклы зат һәм илаһ юк икәнлегенә һәм Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләнең илчесе икәнлегенә таныклык бирәм».*

**Шәһадәт** – ул кешене ислам диненә кертүче формула. Шәһадәтне ишетелерлек итеп (кычкырып) әйткәнчегә кадәр кеше мөселман булып саналмый. Мөселман әти-әнидән туган, яки әтисе яисә әнисе мөселман булган бала мөселман булып санала.

**Шәһадәтнең мәгънәсен аңлап укырга кирәк.** Галимнәрнең барысы да бер фикердә ки, әгәр дә шәһадәтне һичьюгы гомуми мәгънәсенә төшенеп кенә булса да әйтмәсәң, ул әле сине Исламга алып кермәячәк.

## Шәһадәтнең беренче өлеше – «Лә иләһә илләллаһү»

**«Лә иләһә илләллаһү»** сүзләре “Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга һәм табынырга лаеклы һичбер илаһ (зат) юк” дигәнне аңлата.

**«Лә иләһә илләллаһү» –** ул кире кагу һәм раслау. Аллаһтан башка теләсә нинди илаһларны кире кагу һәм Аллаһ – «Бер һәм Аның тиңдәше юк» дип әйтү. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: **«Илаһыгыз бары тик бер Аллаһтыр. Аннан башка илаһ юк. Ул мәрхәмәтле, рәхимле»** - (“Бәкара (Сыер)” сүрәсе, 163 нче аять).

Таныклык китерүнең мәгънәсе шунда ки, Мөхәммәд (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) – ул Аллаһның илчесе. Пәйгамбәребезне танып, без аның кушканнары артыннан баруның кирәклеген үзебез өчен кабул итәбез, аның әйткәннәренә ышанабыз һәм ул тыйганнарның барысын да калдырырга (куеп торырга) әзербез.

Әлеге таныклык дөрес булсын өчен, пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) – кешеләр һәм женнәр өчен җибәрелгән Аллаһы Тәгаләнең колы һәм илчесе; ул соңгы пәйгамбәр һәм илче икәнлегенә бернинди шик-шөбһәсез ышанабыз. Мөхәммәд (сгв) – Аллаһы Тәгаләгә иң якын булган кол.

Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай ди: **«Әйт: “Әй, инсаннар, дөрестән дә мин күкләрнең вә Җирнең хуҗасы булган Аллаһ тарафыннан һәммәгезгә җибәрелгән илчемен. Күкләрнең вә Җирнең идарәсе бары тик Андадыр. Аннан башка тәңре юк. Ул терелтә дә, үтерә дә. Шулай булгач, өмми Пәйгамбәр булган илчесенә, Аллаһка вә аның аятьләренә иманып, иман китергәннәр Аллаһка юнәлер һәм тугры юлны табар”, – диген».** (“Әгъраф (Пәрдә, калкулык)” сүрәсе, 158 нче аять).

Аллаһ шулай ук әйтә: **«...- Ул фәкать Аллаһның Рәсүле һәм пәйгамбәрләрнең соңгысыдыр. Аллаһ һәрнәрсәне асылыннан белеп тора»** («Әхзаб (Төркем)» сүрәсе, 40 нчы аять).

Кыскача йомгак ясыйк: шәһадәтнең мәгънәсен аңлап уку кабул ителә һәм ул түбәндәге шартларны истә тотып үтәлергә тиеш.

· Шәһадәтнең мәгънәви әһәмияте. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: **«Син белеп тор: “Аллаһның Үзеннән башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* тәңре булырдай һичберкем, һичбер нәрсә юк, – дигән Хакыйкатьне онытма. Һәм үзеңнең һәм мөселман ирләр белән мөселман хатын-кызларның гөнаһлары ярлыкансын, дип телә. Аллаһ *(көндез)* кайда йөргәнегезне дә, *(төнлә)* кая барганыгызны да белеп тора)»** («Мөхәммәд» сүрәсе, 19 нчы аять).



· Шәһадәтне ишетелерлек итеп (кычкырып) әйтү. Әйләнә-тирәдәгеләр бу кеше мөселман икәнлекне белсеннәр, һәм аның карарларын Шәригатькә мөнәсәбәттә куллансыннар өчен шәһадәтне кычкырып әйтү мәҗбүри.

· Шәһадәтне тулысынча инанганлык һәм ихласлык белән әйтү. Әбу Һөрәйрә Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) болай дип әйткәнен җиткерә:

# КОРЪӘН – ИСЛАМНЫҢ ИҢ ТӨП ЧЫГАНАГЫ

## 2012 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ

**Коръән - Аллаһның сүзедер. Коръәни-Кәрим - пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаху галәйһи вә сәлләмгә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Җәбраил фәрештә аша (Аллаһ аны ярдәменнән ташламасын!) егерме өч ел буе иңдерелгән Изге Китаптыр. Бу - алдан күрүнең мәңгелек шаһиты, һәм аннан алда булган Изге Язмаларның биниһая хак икәнлекләрен раслаган, Аллаһның соңгы кануннарын җирдә урнаштыра барган соңгы илаһи Сүздер.**



Коръән - мөселман тәгълиматы вә хокукының, әдәп-әхлак кагыйдәләренең төп чыганагыдыр. Бу Изге Китапның тексты, эчтәлеге буенча да, текстының төзелеше буенча да - Аллаһның үз Сүзләредер. Коръән тексты барлыкка килүгә бер генә бәндәнең дә катнашы юктыр. Андагы һәр сүзнең мәгънәсе, бар җиһанда бара торган вакыйгалар турындагы мәгълүматларны саклаган Изге Язмаларның илаһи архетибы булып торган Мәңгелек Китаптагы язмаларга туры киләдер. Коръәнне Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештә (Аллаһ аны ярдәменнән ташламасын!) аркылы Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) күңеленә салган, ә ул бу сүзләрне хәтерендә калдырган һәм аларның тирәнтен мәгънәсен үзләштергән. Җәбраил фәрештә (Аллаһ аны ярдәменнән ташламасын!) кайвакыт Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) алдына кеше рәвешендә килеп баскан. Сүзләрнең Мөхәммәд пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) шул рәвештә иңдерелүенә аның сәхабәләре шаһит булганнар. Ә кайбер вакытта фәрештә табигый тышчага ия булмыйча, илаһи тавыш булып ишетелгән. Иңдерелүләрнең бу иң авыр төре булган. Бу мизгелләрдә Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) йөзен тир каплап алган. Изге Язмалар Мөхәммәд пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) башка төрдә дә иңдерелгәннәр.

Бу вәхиләр Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын!) гарәп дөньясындагы ижтимагый һәм мәдәни үзенчәлекләр шартларында башкарылган акыл һәм психик үзенчәлекләр нәтиҗәсе дип белдерүләрнең, шуңа охшаш теләсә нинди белдерүләрнең, - үз файдаларына бер генә дәлилләре дә юк.

Коръәннең исеме. Күпчелек галимнәр "Коръән" сүзенең, мәгънәсен аңлата торган кара-а фигыленнән барлыкка килгән дип исәплиләр. Анда аятьләрдән торган сүрәләр, алардагы хак фикерләр һәм акыллы киңәшләр җыелган; аларны уку исә, гаҗәеп рухи чистарынуга һәм тынычлануга мөмкинлек бирә.

Изге Коръәндә аның тирән мәгънәви эчтәлеген һәм үзенчәлекләрен чагылдырган башка исемнәр дә телгә алына. Араларында иң киң таралганы - Китаб (Китап).

Шулай ук Зекер (Искә төшерү), Фуркан (Аеручы) исемнәрен куллану да очрый. Коръәннең бу исеме аның яхшыны яманнан, хакны нахактан, хәләлне хәрамнан аеруы белән бәйле.

Коръәннең, гарәп телендә кулланылышта йөргән башка исемнәреннән Тәнзил (Иңдерелеш), Борһан (Исбатлаучы), Хаккъ (Дөреслек), Нур (Яктылык) һәм башкаларны күрсәтергә була. Югарыда санап үтелгән һәр эпитет та Коръәннең гарәпчә текстында очрый, ә Коръән тексты язылган китапның үзен, гадәттә, мөсхәф (күплектә - мөсәхиф) дип атаганнар.

Коръәннең мөселманнар тормышында тоткан урыны. Коръәнне иңдерүнең төп максаты - бәндәләрне хак юлга, әхлакый чистарыну һәм рухи камиллеккә ирешүгә юнәлтү. Ә хак юлга омтылыш һәр инсанда да табигый.

Коръән яхшыны яманнан аерырга өйрәтә. Аның хакыйкый аятьләре ышандырырлык дәлилләр һәм кирекаккысыз исбатлаулар белән раслана. Алар "сынама, иманыңа кил" кагыйдәсен кире кагып, "сынап кара, аннан иманыңа кил" дигән яңа тормыш таләбен игълан итәләр. Коръәндә болай диелгән (мәгънәсе): "Гауга чыганагы булган бәхәсле мәсьәләләрне яхшылап аңлатып бирерсең дип, иман китергән халыкка тугры һәм хәерле юл булсын дип, Без сиңа бу Китапны иңдердек". ("Нәхел (Бал корты)" сүрәсе, 64 нче аять).

Коръән гарәп телендә аңлаешлы итеп иңдерелгән, гаҗәеп аһәңе, анык теле, композицион төзеклеге, грамматик конструкцияләренең дөреслеге белән аерылып тора.

Коръәндә бер генә артык та, очраклы фикер дә юк. Ә аның мәгънәсе турында уйланулар, - иң лаеклы шөгыльләрдән санала. Коръәндәге хакыйкать турында уйланулар күңелгә ачыклык кертә, үзенең чиксез тирән мәгънәсе белән укучыны гаҗәпләндерә. Коръән безне урап алган дөнья гүзәллегенең кадерен белергә өйрәтә, Аллаһы Тәгалә безне тәүбәгә килсеннәр дип җибәрелгән андагы билгеләр турында уйланырга мәҗбүр итә. Коръәндә (мәгънәсе): "Әлиф. Ләм. Ра. Раббының рөхсәте белән инсаннарны караңгылыктан яктылыкка әйдәп, һәр нәрсәне җиңүче, мактауга лаек Аллаһның юлына чыгару өчен сиңа иңдергәнебез бер Китап ул - Коръән", - диелгән ("Ибраһим" сүрәсе, 1 нче аять).

Шуңа да Рәсүлуллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Коръәнне өйрәнүчеләр, аны башкаларга да өйрәтүчеләр - минем иң яхшы дәвамчыларым булырлар дип аңлаткан.

Коръәннең үзенчәлекләре. Изге Коръән - бар кешелек дөньясына мөрәҗәгать буларак иңдерелгән Изге Китап. Анда күрсәтелгән рухи чистарыну юлы шулкадәр камил ки, - аның әһәмияте безнең көннәргәчә югалмаган, һәм ахыргы заманга кадәр югалмаячак та. Менә ни өчен Мөхәммәд Пәйгамбәребезгә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): "- Иң яхшы шаһитлек нинди шаһитлек? - дип сора һәм болай дип җавап бир: минем белән сезнең арагызда Аллаһ шаһит, - диген. - Бу Коръән сезне һәм балигълыкка ирешкәннәрне кисәтер вә нәсихәтләү өчен миңа иңдерелде. Аллаһ белән бергә башка илаһларның да булганлыгынамы сез шаһитлек итәсез? - диген. - Мин (ул эшкә) шаһитлек итмим, - диген, тагын әйт: - Ул - бердәнбер Аллаһ. Мин Аллаһка тиңләштерелгән нәрсәләрдән ерак торам, - диген", - дип әйтергә кушылган ("Әнгам (Мал-туар)" сүрәсе, 19 нчы аять). Мөселман галимнәре бу Изге Язмаларның уникаль булганлыгын күрсәтә торган кайбер үзенчәлекләр турында искәртәләр.

Коръән бервакытта да үзгәртелмәячәк, ничек иңдерелгән булса, шул хәлдә сакланачак, чөнки Аллаһы Тәгаләбез әйткән (мәгънәсе): "Коръәнне Без иңдердек. Бу -

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

---

**«Мин Аллаһтан башка бернинди илаһ юк икәнлегенә таныклык китерәм, һәм Мөхәммәд (сгв) – Аның илчесе һәм колы. Әгәр дә кол әлеге ике таныклыкка ия булган һәм аның дөреслегенә шикләнмәгән хәлдә Аллаһ белән очраша икән (үлгәннән соң), ул Җәннәткә керәчәк».** Ышанычлы җыентыкларда Утба ибне Мәликтән Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) болай дип әйткәне китерелә: **«Җәһәннәм утын Аллаһы Тәгалә Аның ризалыгы өчен ихлас күңелдән «Лә иләһә илләллаһү» дип әйтүчеләргә тыячак».**

· Шәһадәтне Аллаһка һәм Аның Рәсүленә (сгв) мәхәббәт белән уку. Мәхәббәт Аллаһны да олылау булып тора. Аллаһ һәм Аның илчесен мыскыллау, хурлау, көлү, шаярту, мәсхәрәләүнең теләсә нинди чагылышы, ышанычсыз (тәнкыйди) мөнәсәбәттә тору; һәм Аллаһны, һәм Аның Илчесен яратудан һәм олылаудан баш тартуның теләсә нинди формасы кешене ислам диненнән чыгара. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: «***(Рәсүлуллаһ)* син әйт: “Әгәр Аллаһны сөйсәгез, миңа иярегез *(Исламны кабул итегез)*. Аллаһ та сезне сөяр вә гөнаһларыгызны ярлыкар, – диген. Аллаһ мәрхәмәтле ярлыкаучы”»** («Әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе)» сүрәсе, 31 нче аять). Әнәс Пәйгамбәребезнең (сгв) болай дип әйткәнен җиткерә: **«Бары тик өч сыйфат белән аерылып торучылар гына иманның тәмен татыр: Аллаһны һәм Аның илчесен бар нәрсәдән дә күбрәк яратучылар…».**

· Аллаһның кушканнарын үтәп һәм тыйганнарыннан тыелып барырга сүз бирү.

· Сөннәт буенча бару һәм башка кешеләрнең сүзләренә караганда, беренче чиратта Пәйгамбәребез (сгв) сүзләренә өстенлек бирү карарына килү.

## Шәһадәтнең әһәмияте

Шәһадәт – ул диннең нигезе, аны әйткәннән соң кеше мөселман була. Дингә килү – гөнаһларны юкка чыгаручы гамәл булып тора һәм ул мөселман кешесенә Җәннәткә әләгү һәм җәһәннәмдән котылу өчен сәбәп. Әгәр дә үлчәүнең бер ягына җиде күкне һәм җирне, ә икенче ягына **«Лә иләһә илләллаһү Мүхәммәдәр расүлүллаһ»**ны куйсак, соңгысы өстенрәк чыгачак. Кем дә кем иман белән таныклык китерсә һәм бар тормышын шәһадәткә таянып үткәрсә, ул, Иншә Аллаһ, Җәннәттә булыр. Шәһадәтне мөмкин кадәр ешрак әйтү мәслихәт.

Җан бирер алдыннан, экстремаль шартларда, тормыш куркыныч астына куелганда шәһадәтне уку бик тә мөһим.

## Ислам динен ничек кабул итәргә?

Ислам динен кабул итү өчен мәчеткә баруның яки юынуның, суда коенуның һ. б. зарурлыгы юк, бары тик калебең белән ышанырга һәм чын күңелдән шәһадәтне укырга кирәк: ***«Әшһәдү әллә* иләһә илләлла*һү вә әшһәдү әннә Мүхәммәдәр расү*лүлла*һ»*** (* – озын сузыклар). *Тәрҗемәсе: «Мин Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәткә лаеклы зат һәм илаһ юк икәнлегенә һәм Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләнең илчесе икәнлегенә таныклык бирәм».* “Әшһәдү” сүзе “мин таныклык бирәм” дигәнне аңлата, шунлыктан, шәһадәтне “әшһәдү” сүзеннән башка да әйтергә мөмкин: **«Лә иләһә илләллаһү Мүхәммәдәр расүлүллаһ». Ләкин “әшһәдү” сүзен әйтсәк күркәмрәк булыр.**

Әлеге сүзләрне чын күңелдән әйткәннән соң мөселман буласың һәм синең тормышың өр-яңа биттән башлана, моңа хәтле кылган барлык гөнаһларың юкка чыга. Әмир бине Әсадтан (Аллаһ аннан разый булса иде) риваять ителә: «Бервакыт мин Пәйгамбәребезгә (сгв) килдем һәм ул әйтте: **«Миңа тотыну өчен үзеңнең уң кулыңны бир!» Һәм ул миңа үзенең кулын сузды. Ә мин сузмадым һәм ул шулчак әйтте: «Синең белән ни булды, Әмир?» Мин шарт куярга теләвемне әйттем. Пәйгамбәр (сгв) сорады: «Син нинди шарт куярга теләдең?» Мин әйттем: «Минем барлык гөнаһларым да ярлыканса иде». Шуннан соң ул әйтте: «Әллә сиңа билгеле түгелме, Ислам үзенә хәтле булганнарның барысын да гафу итә бит?»»** (Мөслим).

Ислам динен кабул иткәннән соң госел алу (бөтен тәнне юу) мөстәхәб (күркәм) булыр.

**ИСКӘРМӘ:**

Дин галимнәре күрсәткәнчә, шәһадәт мәгънәсенә туры килгән башка сүзләр әйтү – шулай ук җитә, хәтта ул гарәп телендә әйтелмәсә дә, диләр. Имам Әрдабили “Әнвәр” китабында яза: **«Ислам динен кабул итү турында таныклык сүзләрен әйтү теләсә нинди телдә дөрес санала».**

**«Лә иләһә илләллаһү Мүхәммәдәр расүлүллаһ»** кәлимәсе Исламга алып кереп кенә калмый, без аңа, үзебезнең тормыш ориентирларыбызны һәм карашларыбызны туры китереп, гомер буена тугры калырга тиешбез.

***Рафикъ хәзрәт МИҢНӘХМӘТОВ,***
***Татарстанның көнчыгыш төбәге казые,***
***Әлмәт районы һәм шәһәре имам-мөхтәсибе***

## ЧЫН КЕШЕ

**2009 елда изге Рамазан ае алдыннан, мөселманнарыбызны сөендереп, Мамадышта өченче мәчет ачылган иде. Аны шәһәребездә туып үскән, ил күләмендә танылган галим, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Хәмит Ясәвиев хәләл акчасына җиткерде.**

Лаеклы ялга чыккач, Мамадышка кайтып яши башлаган күренекле фән эшлеклесе мәчет салу эшенә 2007 елда ук керешкән иде. Төзелеш өчен кирпечләрне Ижау шәһәреннән үк кайтартты. Мәчетне ачу тантанасында районның имам-мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миңнегалиев: "Аллаһ йорты матур урында салынган. Эченә керсәң, үзеңне Нух көймәсендәге кебек хис итәсең. Мәчетләребез тормышыбыздагы явызлык күренешләреннән котылу, миһербанлыкка, иманлыкка юл күрсәтү урыны булса иде", - диде. Мәчеткә Хәмит абыйның бабасы Әхмәт Ясәви исеме бирелде. Ул бик диндар кеше булган. Хәмит абый: "Мәчеткә кеше күп йөрсен иде", - дигән теләген җиткерде. Изге йортларны төзү белән генә эш бетми әле. Гыйбадәтханәләрнең заллары Аллаһ юлындагы кешеләр белән тулып торганда гына мәчет төзелде дип әйтергә мөмкин. Һәрхәлдә, Хәмит абый Ясәвиев шулай дип саный. Ул башкарган хәйрия эшләре шактый. 1995 елда Сургут шәһәрендәге тәүге мәчетнең төзелешенә иганәлек итә ул. Аннан соң шул ук шәһәрдә икенче мәчеткә нигез салуда булыша. Хәмит абый тәкъдиме белән Мамадыштагы Әхмәт Ясәви мәчетендә мәктәп яшендәге балалар арасында Коръән уку бәйгеләре еш уздырыла. 2010 елда изге Рамазан аенда Хәмит абый аеруча шаккатырды: мәчеткә тәравих намазына килгән һәрбер кешегә һәр көнне йөзәр сум сәдака өләште. Һәр елны йөзгә якын кешегә ифтар мәҗлесе үткәрә ул. Быелгысы 15 августта оешкан төстә үтте. Хәмит абый Ясәвиевкә 2009 елда "Мамадышның мактаулы гражданины" исеме бирелде.



**Фирая МИНГАЛИЕВА,**
**Мамадыш шәһәре**

# КОРЪӘН – ИСЛАМНЫҢ ИҢ ТӨП ЧЫГАНАГЫ

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Хакыйкать. Әлбәттә, аны Без үк саклаячакбыз да" ("Хиҗр (Хиҗыр иле)" сүрәсе, 9 нчы аять).

Илаһи Сүзләр тезмәсен төгәлләп, Коръән, алда иңдерелгән Изге Китаплар турында да шаһитнамә бирә, аларның Аллаһ тарафыннан иңдерелгән булуын дәлилли (мәгънәсе): "Бу Китап (Коръән) шәһәрләребезнең анасы (Мәккәдә) һәм аның тирәсендә яшәүче кешеләрне кисәтер өчен, сиңа иңдерелде вә ул - үзеннән элек килгән китапларны дөресләгән мөбарәк Китаптыр. Ахирәткә инанганнар моңа да (Коръәнгә) ышанырлар шәт һәм алар намазларын дөресләп укуларын дәвам итәрләр" ("Әнгам (Мал-туар)" сүрәсе, 92 нче аять).

Коръәннең чагыштырырлык тиңе юк. Бүгенге көнгә кадәр әле беркемнең дә, эчтәлеге буенча да, төзелү рәвеше буенча да, аңа охшаш, хәтта иң кечкенә генә бер сүрәсенә охшаш булса да, безнең нинди дә булса берәр фикер (текст) яза алганы юк, һәм булмаячак та. Андагы хакыйкатьләр безнең көннәрдә дә фәнни ачышлар белән расланалар.

Коръән сүрәләрен гарәп телен белмәгән кешеләр дә хәтерендә җиңел калдыра ала. Коръән алдан иңдерелгән Изге Язмаларның асылын тапшыра.

Коръәннең тагын бер үзенчәлеге: анда, өлешчә, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) һәм аның сәхабәләре тормышына кагылышлы кайбер вакыйгаларның (сүрә һәм аятьләрнең) да иңдерелүе. Бу аларга тынычлану һәм иман таратуда өмет, ышаныч биргән.

**Г.НУРИЕВ, Н.САБИРҖАНОВ**

## *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 18.08.12 | 3:52 | 5:22 | 13:02 | 17:49 | 20:12 | 21:42 |
| *Якшәмбе* | 19.08.12 | 3:54 | 5:24 | 13:02 | 17:47 | 20:09 | 21:39 |
| *Дүшәмбе* | 20.08.12 | 3:56 | 5:26 | 13:02 | 17:45 | 20:07 | 21:37 |
| *Сишәмбе* | 21.08.12 | 3:58 | 5:28 | 13:02 | 17:43 | 20:04 | 21:34 |
| *Чәршәмбе* | 22.08.12 | 4:00 | 5:30 | 13:02 | 17:42 | 20:02 | 21:32 |
| *Пәнҗешәмбе* | 23.08.12 | 4:01 | 5:31 | 13:02 | 17:41 | 20:00 | 21:30 |
| *Җомга* | 24.08.12 | 4:03 | 5:33 | 13:02 | 17:39 | 19:57 | 21:27 |
| *Шимбә* | 25.08.12 | 4:05 | 5:35 | 13:02 | 17:37 | 19:55 | 21:25 |






# Казан ислам көллияте укырга чакыра

***Казан ислам көллияте IX-XI сыйныфларны тәмамлаган егетләрне укырга чакыра. Урта профессиональ дини белем бирүче уку йорты - Казан ислам көллияте 2003 елда ачыла. Көллият 1880 елда төзелгән тарихи бинада урнашкан. Заманында бу бинада "Мәрҗәния" мәдрәсәсе була. Дәресләрне мәшһүр татар галиме, тарихчы, хөрмәтле остаз Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗәни (1818-1889) алып бара.***

Шиһабетдин хәзрәт уку барышын үзгәртә. Ул дини дәресләрдән тыш дөньяви фәннәр укытуны да кертә. Әлеге мәдрәсәдә Габдулла Апанаев, Салих Сәйдәшев, Морат Рәмзи кебек галимнәр һәм сәнгать эшлекләре дә белем алганнар. Кайбер мәгълүматлар буенча, бу мәдрәсәдә бөтен мөселман дөньясында билгеле булган атаклы татар галиме, фикер иясе Муса Җаруллаһ Бигиев та укыган.

Октябрь революциясеннән соң әлеге бина совет хакимияте тарафыннан тартып алына һәм коммуналь торакка әйләнә, ә соңынннан бөтенләй ташландык хәлдә кала. Әлеге тузып беткән корылманы яңадан торгызу өчен, аны җимереп бу урында яңа бина төзү зарури була. Шулай булса да, Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдин, корылманың тарихи кыйммәтен истә тотып, әлеге бинаны төзекләндерү кирәк дигән фикер белдерә.

Казан ислам көллияте шәһәребезнең тарихи урынында, Иске татар бистәсе - Кабан күле буенда урнашкан. Шәкертләр өч ел дәвамында белем алалар. Әлеге көллият тә, республикабызның башка мәдрәсәләре кебек үк, имам-хатыйблар, ислам нигезләре һәм гарәп теле мөгаллимнәре әзерли. Көллияткә РФ һәм БДБ илләреннән дә 25 яшькәчә ир-егетләр кабул ителә. Башка мәдрәсәләрдән аермалы буларак, көллияттә гарәп һәм татар телләре белән беррәттән, төрек теле дә укытыла. Дәресләрне Татарстан Республикасы, Россия һәм Урта Азия, Сүрия һәм Төркия югары уку йортларын тәмамлаган укытучылар алып бара. Яхшы укыган шәкертләрне Төркиягә белем алырга җибәрү дә каралган. Студентлар барлык кирәк-яраклар белән дә тәэмин ителәләр һәм китапханә, компьютер классы белән файдалана алалар.

Көллиятнең уку планы өч өлештән тора: дини (Коръән, ислам тәгълиматы, фикъһе, тәфсир һ. б.), гомуми белем бирү (тарих, психология, педагогика һ. б.) һәм телләр өйрәнү (татар, рус, төрек, гарәп) дәресләре.

Укудан тыш, шәкертләр спорт белән шөгыльләнәләр, спорт комплексларына йөриләр, төрле бәйге-чараларда катнашалар.

Көллияттә дин дәресләре (Коръән, фикъһе, гакыйдә һ. б.), татар, рус, гарәп һәм төрек телләре укытыла. Шәкертләргә барлык уңай шартлар тудырылган (уку, ашау, тору мәдрәсә хисабына).

***

**Көллияткә укырга керергә теләүчеләргә кирәкле документлар:**
*** аттестат;**
*** сәламәтлек турында белешмә, флюорография (Ф-086);**
*** паспорт, ИНН, полис;**
*** 6 фото (3х4);**

20-30 август көннәрендә Казан ислам көллияте бинасында абитуриентлар өчен кабул итү комиссиясе эшләячәк.

Адрес: 420021 Казан шәһ., Зәйни Солтан ур., 6/15 нчы йорт (Мәрҗани мәчете янында).

***Белешмәләр өчен телефон: +7 (843) 293-81-51; 89274390870.***
**Көллиятнең сайты: www.kikrt.com , электрон почта: kikrt@inbox.ru.**

# БУА МӘДРӘСӘСЕ

***422430, Татарстан Республикасы,***
***Буа шәһәре, К.Либкнехт урамы, 79 нчы йорт***
***Телефон: +7 (84374) 3-70-71, 89276735357;***
***факс: +7 (84374) 3-73-96***
***Электрон почта: islam-buinsk@mail.ru.***



**БУА МӘДРӘСӘСЕ** *- 1805 елда ачылган иң борынгы дини уку йортларының берсе. Биредә татар халкының күп кенә танылган дин әһелләре, мәдәният, мәгариф һәм фән эшлеклеләре укый. Алар арасында Һади Атласи, Зариф Бәшири, Гомәр Толымбай, Бакый Халидов, Габдрахман Таһирҗанов, Ибраһим һәм Касыйм Биккуловлар, Гарифҗан Вәлиди, Шакир Мөхәммәдов, Фатих Мортазин, Камаретдин Салихов һ.б. исемнәре бар. Ул заманында иң танылган мәдрәсәләрдән була. Совет елларында ябыла.*

***1997 елны Буа мәдрәсәсе яңадан үз эшчәнлеген башлый. Анда көндезге һәм кичке бүлекләрдә уку-укыту алып барыла.***

**МӘДРӘСӘНЕҢ ТӨП МАКСАТЫ**

Яшьләргә дини һәм дөньяви белем бирү, җәмгыятебезгә әхлаклы, белемле яшь буын тәрбияләү, дини һәм дини булмаган оешмалар, уку йортлары өчен квалификацияле белгечләр әзерләү.

Көндезге бүлеккә IX-XI сыйныфны тәмамлаган егетләр алына. Мәдрәсәдә уку, яшәү һәм ял итү өчен бөтен шартлар тудырылган.

**ШӘКЕРТЛӘРГӘ:**
- түләүсез тулай торак;
- бушлай көненә 3 тапкыр туклану;
- китапханә, спортзал, бассейн каралган.

**ШУЛАЙ УК:**
- машина йөртү таныклыгы (А, В, С категорияләре),
- IX-X сыйныфтан килүчеләргә урта белем хакында аттестат бирелә.

Мәдрәсәнең уку программасына Коръән, тәфсир, гакыйдә, хәдис, фикъһе, сира, әхлак һ. б. дини фәннәр белән беррәттән, тарих, педагогика, психология, риторика, физкультура, гарәп һәм татар телләре кебек фәннәр кертелгән.

Көндезге бүлектә уку вакыты - 3 ел.

**УКУ ЙОРТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАРГА:**

* "Имам-хатыйб", "Ислам дине фәннәре һәм гарәп теле укытучысы" белгечлеге буенча диплом бирелә;

* Татарстанның югары уку йортларында укуларын дәвам итү мөмкинлеге тудырыла. Теләге булганнар Россия ислам университетының шәригать һәм теология факультетының III курсында укуларын дәвам итә ала;

* имам-хатыйб вазифасында эш белән тәэмин ителә.

Мәдрәсәнең кичке бүлегенә барлык теләүчеләр кабул ителә. Биредә ислам дине нигезләре, гарәп теле, әхлак укытыла. Укулар 1 октябрьдән башланып, май аена кадәр дәвам итә.

Мәдрәсәдә дәресләрне югары дини һәм дөньяви белемгә ия булган мөгаллимнәр алып бара.

Уку-укыту Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгән 322391 нче номерлы лицензия һәм Устав нигезендә алып барыла.

***УКЫРГА КЕРГӘНДӘ ТҮБӘНДӘГЕ ДОКУМЕНТЛАР КИРӘК:***
***1. Директор исеменә гариза.***
***2. Укыганлыкка документ - аттестат яки диплом.***
***3. Туу турында таныклык яки паспорт күчермәсе.***
***4. Медицина белешмәсе (№ 086 "У").***
***5. 3х4 үлчәмле 4 фотокарточка.***
***6. Укыган җирдән характеристика.***
***7. Имам-хатыйб тарафыннан юллама.***

***Документлар көндезге уку бүлегенә 15 июннән 31 августка чаклы, ә кичке бүлеккә 20 августтан 30 сентябрьгә кадәр кабул ителә.***

***БУА МӘДРӘСӘСЕНӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!***

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 7 (150) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9412.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 16 август көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).